| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.11.2019 Казан шәһәре № 392

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 332 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында» 2006 елның 16 июнендәге 310 номерлы карарын көчен югалткан дип тану турында» 2019 елның 16 сентябрендәге 834 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын чыгарылуга бәйле рәвештә

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 332 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.06.2016 № 164, 25.05.2018 № 163, 25.10.2018 № 305 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү

күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерык аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 332 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 22.11.2019 № 392 боерыгы редакциясендә) белән расланды

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: челтәр оешмасы; технологик ялгауны гамәлгә ашыру турында килешү төзү өчен челтәр оешмасына мөрәҗәгать иткән зат; челтәр оешмасы белән технологик ялгау турында килешү төзегән зат (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Дәүләт Комитетының урнашу урыны: Казан шәһәре, К. Маркс ур., 66.

Дәүләт комитетының эш графигы: дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.00 башлап 17.00 кадәр, җомга 8.00 башлап 15.45 кадәр, төшке аш 12.00 башлап 12.45 кадәр; шимбә, якшәмбе – ял.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Дәүләт комитетының эш көннәрендә.

Җәмәгать транспортында «Толстой» тукталышына кадәр килергә.

10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 83, 89, 91, 98 номерлы автобуслар;

2, 3, 5, 7, 8 номерлы троллейбуслар.

Керү – шәхесне таныклаучы документны күрсәтеп.

1.3.2. Дәүләт комитетының технологик ялганган өчен түләүне җайга салу һәм тикшереп тору бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 221-82-45, 221-82-47.

1.3.3. Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – Дәүләт комитетының рәсми сайты) рәсми сайты адресы: http://kt.tatarstan.ru, Дәүләт комитетының электрон почта адресы: kt@tatar.ru.

Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен җаваплы булган Дәүләт комитеты структур бүлекчәсе хезмәткәренең электрон почтасы адресы: Shakirzyanova.Ilvira@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Дәүләт комитеты бүлмәләрендә урнашкан, Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турында мәгълүмат стендлары аша.

2) «Интернет» челтәре аша:

- Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru);

- Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

3) Дәүләт комитетына телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Дәүләт комитетына язмача мөрәҗәгать иткәндә (почта аша яисә «Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы» аша).

1.3.5. Дәүләт комитеты урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Дәүләт комитетының электрон почта адресы турында мәгълүмат Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Дәүләт комитеты биналарында мәгълүмат стендларында дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3-2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 35-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 31.03.2003, № 13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары (алга таба – 861 номерлы карар) белән расланган Электр энергиясен кулланучыларның энергия кабул итү җайланмаларын, электр энергиясен җитештерү объектларын, шулай ук электр челтәрләренә караган электр челтәре хуҗалыгы объектларын технологик тоташтыру кагыйдәләре (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.12.2004, № 52 (2 өлеш), 5525 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 9 гыйнварындагы 14 номерлы карары (алга таба – 14 номерлы карар) белән расланган Технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу органнары билгеләгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне җайга салу кагыйдәләре (алга таба – 14 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 19.01.2009, №3, 414 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары (алга таба – 468 номерлы карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 04.08.2010, №29, 1195 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 08.12.2010, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Дәүләт комитеты җибәргән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән (язу, басма, грамматик) хата;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгать. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы | Технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салу органнары билгеләгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау | 35-ФЗ номерлы федераль закон;<br>14 номерлы карар |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты | 468 номерлы карарның 4.1.10 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яисә өлешчә) канәгатьләндерү яки аларны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар | 14 номерлы карарның 17 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Гаризаны һәм әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны, аларның таләпләргә туры килү-килмәвен билгеләү максатларында алар килгән датадан 7 эш көне эчендә карау һәм гаризаны кабул итү турында яки гаризаны карауга алудан баш тарту турында карар чыгару.<br>Гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында дәлилләнгән карар кабул итү, яисә аларны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул итү – әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кабул ителгән көннән башлап 30 эш көне эчендә, җайга салу органы тарафыннан өстәмә белешмәләр алу яисә бәхәсне карауга башка затларны җәлеп итү һәм (яки) экспертиза үткәрү зарурлыгы булмаган очракта.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү (бәхәсне карау) вакытын туктатып тору вакыты җайга салу органы тарафыннан өстәмә белешмәләр алу | 14 номерлы карарның 11 пункты<br>14 номерлы карарның 17 пункты<br>14 номерлы карарның 14 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | яисә башка затларны бәхәсне карауга җәлеп итү һәм (яки) экспертиза уздыру таләп ителгән очракта, карар кабул ителгән көннән алып 60 көннән дә артмаска тиеш.<br>Күрсәтелгән срокны кабат туктатып тору рөхсәт ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта, электрон адрес, факс буенча) аны кабул иткән көннән соң 5 эш көне эчендә җибәрү. | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | Гариза (1 нче кушымта).<br>Уздырылган вакытны кайтару турында үтенеч язуы (гариза билгеләнгән вакыттан соңрак тапшырылган очракта).<br>Гариза бирүче үз таләпләрен нигезли торган (гариза бирүче фикеренчә) шартларны раслаучы документлар (төп нөсхәләр яки күчермәләр).<br>Гариза һәм документлар ике нөсхәдә тапшырыла.<br>Бәхәскә документның бер өлеше генә кагылышлы булса, аннан таныкланган өземтә тапшырыла.<br>Гариза бирүче тарафыннан бер биттән артык булган кәгазьдә тапшырыла торган барлык документлар номерланырга, тегелгән, соңгы битендә гариза бирүченең мөһере (булган очракта) белән беркетелгән булырга һәм гариза бирүченең яисә аның вәкаләтле вәкиленең имзасы белән расланган булырга тиеш.<br>Гаризаны шулай ук «Татарстан Республикасы Рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы» аша электрон рәвештә дә җибәрергә мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша | 14 номерлы карарның 8, 9, 10 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>почта юлламасы белән.<br>Гариза белән документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | 1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>2. Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә).<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела.<br>Дәүләт комитеты гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза | 14 номерлы карарның 9 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Гаризаның гаризаны тапшыра торган зат үз хокукларының игътибарга лаек булмаган сәбәпләр аркасында белгән яки белергә тиеш булган көннән башлап 90 көн узгач тапшырылуы.<br>2. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>3. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе.<br>4. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>5. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләре күрсәтелмәү.<br>6. Электрон документлар формасында электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) гаризаны һәм документларны | 14 номерлы карар<br><br>210-ФЗ номерлы федераль закон; 63-ФЗ номерлы федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | (документларның күчермәләрен) тапшыру. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәте туктатып торылырга мөмкин, түбәндәгеләр таләп ителгәндә:<br>җайга салу органы тарафыннан өстәмә белешмәләр алу яисә бәхәсне карауга башка затларны җәлеп итү;<br>экспертиза үткәрү. | 14 номерлы карар<br><br>14 номерлы карарның 13 пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | 14 номерлы карар |

| | | |
|---|---|---|
| мәгълүматны да кертеп | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат (гариза бирүче) тарафыннан үзен кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтү, шулай ук дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат (гариза бирүче) тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Югарыда күрсәтелгән көтү вакытына төшке аш вакыты һәм эш вакыты булмаган вакыт кертелми | РФ Президентының 07.05.2012 ел, № 601 Указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза кергән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | 14 номерлы карар |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, | Дәүләт хезмәте түбәндәгеләр белән җиһазландырылган биналарда күрсәтелә:<br>һаваны кондиционерлау системасы белән;<br>янгынга каршы система белән һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен мебель белән;<br>мәгълүмати стенд белән.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итә алу мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Инвалидларга һәм хәрәкәт итү мөмкинлекләре чикләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | затларга дәүләт хезмәтләрен күрсәтү яшәү урыны буенча яисә видеоэлемтә, интернет аша дистанцион режимда гамәлгә ашырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы мәгълүмат мәгълүмат такталарында Дәүләт комитетына төп керү юлы янында һәм гражданнар мөрәҗәгатьләре бүлеге аша керү урынында, гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3) дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт граждан хезмәткәрләренең гамәлләренә прецедентлар (нигезләнгән шикаятьләр) булмау;<br>4) гариза бирүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Гариза бирүче белән үзара хезмәттәшлек итүнең вакыт озынлыгы – 15 минуттан артмый.<br><br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр санала:<br>Дәүләт комитеты бинасының җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документларны кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау мөмкинлеге | дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында Дәүләт комитеты мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны Интернет челтәрендә Дәүләт комитетының мәгълүмат ресурслары ярдәмендә электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында шәхси кабинет аша гариза тапшыру һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу мөмкинлеге (мондый мөмкинлек тудырылганнан соң).<br><br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк (алга таба - КФҮ) аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте КФҮ аша күрсәтелми.<br>Мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге юк.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен | Гаризаны, алга таба документларның төп нөсхәләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша электрон формада тапшыру мөмкинлеге бар (алга таба – Интернет-кабул итү системасы). | |

| | | |
|---|---|---|
| исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru) аша электрон документ формасында гариза бирү мөмкинлеген тормышка ашырганнан соң, дәүләт хезмәте нәтиҗәсе электрон рәвештә бирелә | |
| | | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында, яисә аларны канәгатьләндерүдән баш тарту турында боерык (баш тарту турында хәбәр) әзерләү һәм раслау;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) техник хатаны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчене консультацияләү һәм гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яисә) «Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы» аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек белгече шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яки) хат аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча да, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән үзе, ышанычлы заты, почта аша, Татарстан Республикасы Рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша Дәүләт комитетының гомуми тәэминат һәм эш башкару бүлегенә (алга таба – эш башкару бүлеге) территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

Гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша бирелергә мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар, гариза бирүче үз хокукларын бозу турында белгән яки белергә тиеш булган көннән башлап 90 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза һәм документлар.

3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гариза белән документларны кабул итә;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм «Электрон Хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында (алга таба – электрон документ әйләнеше) теркәү номерын беркетеп һәм кабул итү датасын күрсәтеп терки;

документларны кабул итү датасы, беркетелгән кереш номеры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең датасы һәм вакыты турында тамгалап, гариза күчермәсен почта буенча яки электрон почта (ихтыярына карап) аша гариза бирүчегә тапшыру яки җибәрү;

гаризаны электрон документ әйләнеше аша электрон формада Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) (алга таба – рәис (рәис урынбасары) җибәрү.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм рәискә (рәис урынбасарына) җибәрелгән гариза.

3.3.3. Рәис (рәис урынбасары) гаризаны карый һәм рәис урынбасарына карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен рәис урынбасарына җибәрелгән гариза.

3.3.4. Рәис урынбасары гаризаны карый һәм Бүлек башлыгына карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен Бүлек башлыгына җибәрелгән гариза.

3.3.5. Бүлек башлыгы гаризаны һәм документларны карый, җаваплы башкаручыны (алга таба – Бүлек белгече) билгели һәм гаризаның 14 номерлы карар белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен билгеләү максатында аңа җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган гариза һәм документлар.

3.4. Ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Бүлек белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә белешмәләр тапшыру турындагы рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында гарызнамәләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр, законнарда билгеләнгән чорда, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр (алга таба – документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр) җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән, соратылган белешмәләр яки документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәр.

3.5. Гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында, яисә аларны канәгатьләндерүдән баш тарту турында боерык (баш тарту турында хәбәр) әзерләү һәм раслау.

3.5.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

норматив хокукый базаны һәм бәхәсләрне карау буенча гаризада билгеләнгән проблема буенча килеп туган хокук куллану практикасын исәпкә алып, документларны өйрәнә һәм карап тикшерә;

гаризаны карауга алудан баш тарту яки кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли;

карарны бүлек җитәкчесенә килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергәннән соң 7 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә юнәлдерелгән гаризаны карауга алудан баш тарту турында карар проекты.

3.5.2. Бүлек башлыгы карар проектын карый, килештерә һәм Дәүләт комитеты рәисенә (рәис урынбасарына) килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура 3.5.1 пунктта каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Дәүләт комитеты рәисенә килештерү өчен юнәлдерелгән карар проекты.

3.5.3. Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) карар проектын карап, гаризаны карауга алу яисә кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм әлеге карарны гариза бирүчегә җибәрү өчен Эш башкару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаны карауга алудан баш тарту яки кабул итүдән баш тарту турында карар проекты (баш тарту турында хат).

3.5.4. Эш башкару бүлеге белгече кабул ителгән карарны терки һәм аның күчермәсен гариза бирүчегә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә җибәрелгән карар күчермәсе.

3.5.5. Бүлек белгече, гаризаны карауга алу турында карар кабул ителгәннән соң, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

технологик ялганганн өчен түләүне куллануның дөреслеген тикшерә. Өстәмә мәгълүмат алу яисә бәхәсне карау өчен башка затларны җәлеп итү яки өстәмә

экспертиза үткәрү кирәк булган очракта, әлеге Регламентның 3.5.6-3.5.7 пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла;

әлеге киңәшмә кысаларында карала торган бәхәс буенча материалларны Дәүләт комитетының юридик бүлегенә җибәрә;

телефон элемтәсе һәм (яки) яклар адресына факсограмма юллау аша бәхәсне карау буенча киңәшмә (алга таба – киңәшмә) көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

гаризаны, гариза бирүченең документларын, килеп туган бәхәс буенча бәяләмәне, киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы белгечкә гаризаны карауга алу турында карар җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң 8 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: якларга һәм юридик бүлек белгечләренә бәхәсне карау датасы турында хәбәр итү; киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы белгечкә юнәлдерелгән материаллар.

3.5.6. Бүлек белгече:

өстәмә мәгълүмат алу яисә бәхәсне карау өчен башка затларны җәлеп итү кирәклеге турында һәм (яки) гариза бирүче адресына документларга өстәмә экспертиза билгеләү турында белдерү әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, өстәмә белешмәләр алу яисә башка затларны бәхәсне карауга җәлеп итү кирәклеге турында карар кабул ителгәннән соң һәм (яисә) тапшырылган документларга өстәмә экспертиза билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче адресына җибәрелгән хәбәр.

3.5.7. Бүлек белгече өстәмә белешмәләр алу яисә башка затларны бәхәсне карап тикшерүгә җәлеп итү кирәклеге турында яки тапшырылган документларга өстәмә экспертиза үткәрү турында карар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

өстәмә мәгълүмат ала, өстәмә экспертиза нәтиҗәләрен ала яки бәхәсне карау өчен башка затларны җәлеп итә;

бәяләмә проектын әзерли;

Бүлек башлыгына килештерү өчен бәяләмә проектын җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар өстәмә белешмәләр алу яисә башка затларны бәхәсне карауга җәлеп итү турында карар кабул ителгән көннән соң 60 көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләмә проекты.

3.5.8. Бүлек белгече, өстәмә белешмәләр һәм (яки) экспертиза бәяләмәсен алып, әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында каралган процедураны гамәлгә ашыра.

3.5.9. Киңәшмәне үткәрү өчен җаваплы белгеч киңәшмәдә катнашучы затларны теркәүне һәм киңәшмәдә катнашучылар исемлеген рәискә (рәис урынбасарына) тапшыруны тәэмин итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура киңәшмә көнендә, ул башланыр алдыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәислек итүче затка тапшырылган киңәшмәдә катнашучылар исемлеге.

3.5.10. Рәис (рәис урынбасары) киңәшмә уздыра, аның нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яки өлешчә) канәгатьләндерү турында рәиснең (рәис урынбасарының) тиешле боерыгы проектын әзерләү зарурилыгы турында;

- рәиснең (рәис урынбасарының) гаризада күрсәтелгән таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында тиешле боерыгы проектын әзерләү зарурилыгы турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура киңәшмә узган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәиснең (рәис урынбасарының) таләпләрне канәгатьләндерү яки таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында карары, киңәшмәнең рәсмиләштерелгән беркетмәсе.

3.5.11. Киңәшмә нәтиҗәләре буенча киңәшмә үткәрү өчен җаваплы белгеч:

киңәшмәдә каралган мәсьәләләрне карау беркетмәсен, кабул ителгән карарлар турында мәгълүматны үз эченә алган бәхәсне карау беркетмәсен тутыра;

гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яки өлешчә) канәгатьләндерү яки таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында боерык проектын әзерли;

беркетмәне һәм боерык проектын рәискә (рәис урынбасарына) раслауга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура киңәшмә уздырылган көннән алып ике эш көне эчендә тормышка ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: киңәшмәнең рәсмиләштерелгән беркетмәсе, рәискә (рәис урынбасарына) юнәлдерелгән боерык проекты.

3.5.12. Дәүләт комитеты рәисе (рәис урынбасары) киңәшмә беркетмәсенә имза сала һәм гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яки өлешчә) канәгатьләндерү турында яки таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында боерыкны раслый һәм Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган беркетмә, расланган боерык.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.6.1. Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

боерык күчермәсен якларга җибәрә;

боерыкны Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыру өчен Дәүләт комитетының мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар боерык расланганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: якларга һәм Дәүләт комитетының мәгълүмати-техник хезмәт күрсәтү бүлегенә җибәрелгән гаризада күрсәтелгән таләпләрне (тулысынча яисә өлешчә) канәгатьләндерү турында яки таләпләрне канәгатьләндерүдән баш тарту турында боерык күчермәсе.

3.7. Электрон формада килгән гариза карау

3.7.1. Электрон формада кергән гариза әлеге Регламентның 3.3.2-3.3.5 пунктларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.8. Техник хаталарны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

3.8.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны (язу, хәреф хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза (2 нче кушымта);

гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы (язу хатасы, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документ;

техник хатасы (язу хатасы, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны (язу хатасын, хәреф хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә), яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша җибәрелә.

3.8.2. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы (язу хатасы, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки гариза бирүче адресына почта (электрон почта) аша Бүлеккә техник хатасы (язу хатасы, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу хатасы, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хатас) ачыкланганнан соң яки теләсә нинди мәнфәгатьле заттан җибәрелгән техник хата (язу хатасы, хәреф хатасы, грамматик яки арифметик хата) турында гариза алынганнан соң өч көн дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен

җаваплы булган урынбасары һәм беренче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2 Агымдагы контрольлек Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору, гариза тапшыручыларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерү, карарлар кабул итү һәм гариза бирүчеләрнең Дәүләт комитеты вазыйфаи затлары карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләү.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү Дәүләт комитеты актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Дәүләт комитетының еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла торган) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшерү нәтиҗәләре акт белән рәсмиләштерелә, анда ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны юкка чыгару буенча тәкъдимнәр теркәлә.

4.7. Контрольлек нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, Россия Федерациясе законнары нигезендә гаепле затларны җаваплылыкка тарту гамәлгә ашырыла.

4.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар тарафыннан контрольдә тоту Дәүләт комитетына мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында гамәлгә ашырыла торган (кабул ителгән) гамәлләрне (гамәл кылмауны) һәм карарларны югары торучы дәүләт хакимияте органнарына шикаять кылу юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Дәүләт комитеты, Дәүләт комитеты вазыйфаи заты яки Дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл

кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитетына шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә рәис карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.2. Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Дәүләт комитетының рәсми сайтыннан (http://kt.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

гариза бирүченең Дәүләт комитеты, аның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.4. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы гариза бирүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Дәүләт комитетында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу

яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, яки дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Оешманың фирма бланкында (оешма реквизитлары)

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитеты рәисенә
______________________________
(инициаллары, фамилиясе)

**БӘХӘСНЕ КАРАУ ТУРЫНДА ГАРИЗА**

(кемнән)
_____________________________________________________________________
(гариза бирүченең атамасы)
_____________________________________________________________________
(юридик затның урнашкан урыны/физик затның яшәгән урыны)

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетыннан
_____________________________________________________________________,
(үзенә карата гариза тапшырылган затның атамасы, урнашу урыны)

карата респондентның риза булмавына бәйле рәвештә барлыкка килгән бәхәсне каравыгыз турында һәм
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
(Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына сылтама ясап, бәхәс барлыкка килү өчен нигез булган гамәлне, карарны күрсәтергә)
турында таләпне канәгатьләндерүегез турында үтенәм.
Бәхәснең асылы:
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(бәхәснең асылын тулы итеп бәян итү, кайчан һәм нинди гамәлләргә (карарларга) бәйле рәвештә барлыкка килгән, бәхәсне җайга салу буенча нинди дә булса чаралар күрелгәнме)

Гариза бирүче позициясен нигезләү:

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(гариза бирүченең Россия Федерациясе норматив хокукый актларына сылтама ясап, ә берничә респондентка таләпләр булган очракта – аларның һәркайсына булган таләпне күрсәтеп; гаризада күрсәтелгән таләпләр өчен нигез булган шартлар)

Бәхәсне карау өчен кирәкле башка мәгълүматлар:

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

**Кушымта:**

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(теркәлгән документлар исемлеге һәм аларның һәркайсында битләр саны)

Имза

_____________________ ____________________________________

(мөһер урыны) (тулы имза)

«_____» _________________ 20 __ ел.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитеты рәисенә
____________________________________
Кемнән:____________________________

Киңәш ителә торган рәвеше

Техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза

__________________________________________________________ дәүләт хезмәте
(хезмәтнең аталышы)
күрсәтелгәндә җибәрелгән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яисә арифметик хата) турында хәбәр итәм.

Язылган: _______________________________________________________________
___________________________________________________________________________
Дөрес белешмәләр: _______________________________________________
___________________________________________________________________________
Җибәрелгән техник хатаны (язу, басма хаталарын, грамматик яисә арифметик хаталарны) төзәтүне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яисә арифметик хатаны) төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны __________e-mail адресына җибәрү юлы белән;

__________________________________________________ адресы буенча кәгазь документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә(яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның ризалыгын раслыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә һәм минем тарафтан вәкил булган затка кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән дәүләт хезмәтенең сыйфатын бәяләү буенча _____________ телефоны аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм.

____________ _______________(___________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Территориаль бүлә торган электр челтәрләренә технологик ялганган өчен түләү һәм (яки) мондый түләү күләмен билгеләү өчен билгеләнгән тариф ставкаларын (махсуслаштырылган тариф ставкаларын) куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнарның һәм вазыйфаи затларның реквизитлары

| Вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Рәис | (843) 221-82-18<br>(843) 221-82-01 | кt@tatar.ru |
| Рәиснең беренче урынбасары | (843) 221-82-05 | Aleksandr.Shtrom@tatar.ru |
| Җехнологик ялгау өчен түләүне җайга салу һәм тикшереп тору бүлеге башлыгы | (843) 221-82-45 | Shakirzyanova.Ilvira@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында
җаваплы вазыйфаи зат реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы | 8(843) 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov@tatar.ru |